**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2017 Балык Бистәсе штп. № 268пи

2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе тәкъдимен карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Расларга:

-2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

- балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,5 күләмендә төзәтмә коэффициентны.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган нормативлар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы

буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 22
декабрендәге 268 пи
номерлы карары белән
расланганнар

**2018 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар ( 1 укучыга елына, сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | Башлан-гыч һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 50 957 | 59 068 | 76 860 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 28 213 | | 24 536 | 58 933 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 53 529 | 44 144 | 161 039 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 23 410 | | |
| Фольклор сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 50 400 | 48 358 | 78 311 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 77 640 | | 74 287 | | 122 709 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 40 144 | | 37 262 | 37 263 | 59 003 |